СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Үрнәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 48** **“21” август 2019 ел**

## Үрнәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 12 номерлы «Җир салымы турында " карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлек, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Уставы нигезендә Үрнәк авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1.Үрнәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 12 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

-2 нче пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент.”

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан гына үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы И.Р.Камалетдинов

СОВЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ